**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

**Нижнеалькеевского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Түбән Әлки авыл җирлеге**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422881, РТ, с. Нижнее Алькеево ул. Советская, д. 55

Адресы: 422881, РТ, Түбән Әлки авылы, Совет ур., 55

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Түбән Әлки авылы **КАРАР**

2023 нче елның 26 гыйнвар 3 №

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы "Җирләү һәм җирләү эше турында" 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы "Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Әлки авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районы Түбән Әлки авыл җирлегендә 2023 елның 1-февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымта нигезендә **7793,48** сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Әлки авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 25 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Түбән Әлки авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 3номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми //htth:pravo.tatarstan.ru.порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы
Түбән Әлки авыл җирлеге
Башкарма комитеты рэисе вазифаларын
вакытлыча башкаручы Ф.С.Садреев

Түбән Әлки авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 26 гыйнварындагы 3 № карарына 1 нче кушымта

Түбән Әлки авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б № | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 4489,06 |
| 3. | Мәрхүмнең мәетен (калдыгын) зиратка китерү | 1621,04 |
| 4. | Җирләү (каберне казу һәм күмү) | 1683,38 |
| | Барлыгы: | **7793,48** |

Түбән Әлки авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022елның 26 гыйнварындагы 3 № карарына 2 нче кушымта

Түбән Әлки авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән күрсәтелә торган җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифлар

| т/б № | Хезмәтләр, кирәк-яраклар исемлеге | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1. | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. | Кәфенләү | 1497,12 |
| 3. | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2985,70 |
| 4. | Мәрхүмнең мәетен (калдыгын) зиратка китерү | 1621,04 |
| 5. | Җирләү (каберне казу һәм күмү) | 1689,62 |
| | Барлыгы: | **7793,48** |